ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2019 п.г.т.Алексеевское № 26

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алу
планнарын формалаштыру,
раслау һәм алып бару Тәртибен
раслау турында**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында"гы 5 апрель, 2013 ел, 44-ФЗ санлы Федераль законның 21 нче маддәсе, 5 нче өлеше нигезендә һәм "Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып баруга таләпләр, шулай ук товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу планнары формасына таләпләр турында"гы 21 ноябрь, 2013 ел, 1043 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары таләпләрен исәпкә алып,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару Тәртибен (моннан ары – Тәртип) расларга (Кушымта).

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru/) һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен планнарны формалаштыру, раслау һәм алып бару Тәртибен раслау турында"гы 26 сентябрь, 2016 ел, 410 санлы карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольне икътисад буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Д. Васильевка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы башкарма
комитеты карарына кушымта
22.01.2019 № 26

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт система турында"гы 5 апрель, 2013 ел, 44-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба - 44-ФЗ санлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу планнарын (алга таба – сатып алулар планы) формалаштыру, раслау һәм алып бару кагыйдәләрен билгели.

2. Сатып алулар планы 10 эш көне эчендә раслана:

а) муниципаль берәмлек исәбеннән эш итүче муниципаль заказчылар тарафыннан (алга таба - муниципаль заказчылар),

- Россия Федерациясе бюджеты турындагы закон нигезендә йөкләмәләрне кабул итүгә һәм (яки) башкаруга акчага күчереп исәпләгәндә хокуклар күләмен тиешле муниципаль заказчыга җиткергәннән соң;

б) контракт системасы турындагы Законның 15 нче маддәсе, 2 нче һәм 6 нчы өлешләре нигезендә тормышка ашырыла торган сатып алулардан кала, муниципаль берәмлек булдырган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының бюджет оешмалары тарафыннан,

- финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын раслаганнан соң;

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнары әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән кешеләр тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планлаштырылган чорга (чираттагы финанс елы) 44-ФЗ санлы Федераль законның 17 нче маддәсе, 7 нче өлешендә билгеләнгән срокларда, түбәндәге нигезләмәләрне исәпкә алып, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасын (ЕИС) файдаланып формалаштырыла:

а) әлеге Тәртипнең 2 нче пункты, "а" пунктчасында күрсәтелгән муниципаль заказчылар:

1) сатып алу планнарын 44-ФЗ санлы Федераль законның 13 нче маддәсе нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән сатып алуларны гамәлгә ашыру максатларыннан чыгып формалаштыралар һәм аларны алар буенча Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә сатып алуларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре дәлилләрен формалаштыру өчен баш эш итүчеләргә тәкъдим итәләр.

2) бюджет сметалары проектларын төзү процессында сатып алу планнарына һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты турында карар проектын төзегәндә Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә сатып алуларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре дәлилләре белән баш эш итүчеләрнең гаризаларына төзәтмәләр кертәләр.

3) кирәк булганда сатып алуларның формалашкан планнарына төгәллек кертәләр, аларга төгәллек керткәннән һәм акчага күчереп исәпләгәндә хокуклар күләмен муниципаль заказчыга җиткергәннән соң Россия Федерациясенең бюджет турындагы законнары нигезендә йөкләмәләрне кабул итүгә һәм (яки) үтәүгә 44-ФЗ санлы Федераль законның 17 нче маддәсе, 7 нче өлешендә билгеләнгән срокларда сатып алуларның формалаштырылган планнарын раслыйлар һәм бу хакта баш эш итүчегә җиткерәләр;

б) әлеге Тәртипнең 2 нче пункты, “б” пунктчасында күрсәтелгән учреждениеләр:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә аларның финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда сатып алуларның планнарын формалаштыралар;

2) кирәк булганда оештыручыларының вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органнар белән килешү буенча аларның финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары проектларын төзү һәм Россия Федерациясе бюджеты турындагы законнар нигезендә бюджет ассигнованиеләре дәлилләрен тәкъдим итү процессына төзәтмә кертәләр.

3) кирәк булганда сатып алу планнарына төгәллек кертәләр, аларга төгәллек керткәннән һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын раслаганнан соң формалаштырылган планнарны 44-ФЗ санлы Федераль законның 17 нче маддәсе, 7 нче өлешендә билгеләнгән срокларда раслыйлар һәм оештыручыларының вазыйфаларын һәм бу хакта вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органнарга хәбәр итәләр.

4. Чираттагы финанс елына һәм планлаштырылган чорга сатып алулар планы чираттагы елның һәм расланган сатып алулар планының планлаштырылган чорының беренче елы параметрларын һәм аларга өстәлгән планлаштырылган чорның икенче елы параметрларын үзгәртү юлы белән эшләнә.

5. Сатып алу планнары Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты төзелә торган срокка формалаштырыла.

6. Россия Федерациясенең бюджет турындагы законнары нигезендә муниципаль заказчыларның сатып алу планнарына, шулай ук әлеге Тәртипнең 2 нче пункты, “б” пунктчасында күрсәтелгән юридик затларның сатып алу планнарына сатып алулар турында мәгълүмат кертелә, аны гамәлгә ашыру планлы чор дәвамында планлаштырыла. Бу очракта мәгълүмат планлаштырылган сатып алуларның бөтен срогына сатып алулар планына кертелә.

7. Әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән затлар сатып алулар планын 44-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләре һәм әлеге документ нигезендә алып баралар. Сатып алуларның расланган планнарына кирәк булган очракта үзгәрешләр кертү өчен түбәндәгеләр нигез булып торалар:

а) сатып алу планнарын 44-ФЗ санлы Федераль законның 13 нче маддәсе нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән һәм Законның сатып алына торган товарларга, эшләргә, хезмәтләргә (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәтләрнең чик бәясе) таләпләрнең контракт системасы турындагы 19 нчы маддәсе һәм муниципаль органнар һәм алар карамагындагы казна учреждениеләренең вазыйфаларын тәэмин итүгә чыгымнар нормативларына туры китерү;

б) сатып алу планнарын быелгы финанс елына (быелгы финанс елы һәм планлаштырылган чор) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына үзгәрешләр кертү турындагы карарына туры китерергә;

в) сатып алулар планнарын раслаганнан соң кабул ителгән һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты турында карар белән расланган бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртүгә китермәүче Россия Федерациясе Президентының федераль законнарын, карарларын, йөкләмәләрен, күрсәтмәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларын, йөкләмәләрен, Татарстан Республикасы законнарын һәм карарларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарларын, йөкләмәләрен гамәлгә ашыру;

г) мәҗбүри җәмәгатьчелек тикшерүе йомгаклары буенча муниципаль заказчы яки юридик зат тарафыннан кабул ителгән карарларне гамәлгә ашыру;

д) Россия Федерациясе законнары нигезендә сатып алуларны гамәлгә ашырганда алынган экономияне файдалану;

е) 44-ФЗ санлы Федераль законның 99 нчы маддәсендә билгеләнгән контроль органнарының күрсәтмәләр бирүе, шулай ук тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү процедурасын юкка чыгару турында.

8. Сатып алулар планына сатып алулар турында мәгълүмат, шулай ук берәнбер тәэмин итүчедән ( подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алулар турында мәгълүмат, күрсәтелән чор дәвамында төзелергә тиешле контрактлар кертелә.

9. Расланган сатып алулар планы расланганнан яки дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан кала, андый планны үзгәрткәннән соң өч эш көнендә ЕИСда урнаштырылырга тиеш.

10. План-график "Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып баруга таләпләр, шулай ук товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу план-графигы формасына таләпләр турында"гы 21 ноябрь, 2013 ел, 1043 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган форма буенча формалаша.